КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 3 август г.Казань № 938

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2024 елларга һәм 2034 елга кадәр перспективага Татарстан Республикасының нефть-газ химиясе комплексын үстерү программасын раслау турында» 2020 ел, 14 март, 188 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2024 елларга һәм 2034 елга кадәр перспективага Татарстан Республикасының нефть-газ химиясе комплексын үстерү программасын раслау турында» 2020 ел, 14 март, 188 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2020 – 2024 елларга һәм 2034 елга кадәр перспективага Татарстан Республикасының нефть-газ химиясе комплексын үстерү программасында:

4 бүлектә:

дүртенче абзацта «республика министрлыклары һәм ведомстволары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасында химия һәм нефть химиясен үстерүнең өстенлекле юнәлешләрен билгеләү һәм республика дәрәҗәсендә беркетү» бүлекчәсенең алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«алгарышлы үсеш территорияләре (алга таба - АҮТ) һәм МИЗ шартларын куллану;»;

«Инновацион резина һәм пластмасса әйберләрне, Татарстан Республикасында химия продукциясен сынап карау (тестлаштыру) өчен тәҗрибә полигоннары булдыру» бүлекчәсенең өченче абзацында «АСИҮТ» сүзен «АҮТ» сүзенә алмаштырырга;

«Химия һәм нефть химиясе өлкәсендә карьера үсеше һәм инвестицияләр өчен көч куллану ноктасы буларак Татарстан Республикасын популярлаштыру» бүлекчәсенең беренче абзацында «АСИҮТ» сүзен «АҮТ» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин